БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» 12 2020 ел № 349

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә махсус инвестиция контрактын төзү тәртибе турында» Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декаберендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә капитал салулар рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеге турында» 1999 елның 25 февралендәге 39-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм инвестицияләр җәлеп итү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә махсус инвестиция контрактын төзү тәртибе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (территориаль үсеш буенча) йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның «07» 12
349 номерлы карарына
1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә махсус инвестиция контрактын төзү тәртибе турында Нигезләмә

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 31.12.2014 елның 31 декаберендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне стимуллаштыруның аерым чараларын күрсәтү максатларында махсус инвестиция контракты төзү тәртибен билгели.

Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә инвестиция контрактлары төзү шартларын һәм тәртибен билгели.

Әлеге Нигезләмә максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

- инвестиция контракты - Татарстан Республикасының Балтач район башкарма комитеты һәм инвестор арасында якларның хокукларын һәм бурычларын билгели торган шартнамә;

- инвестицияләү объекты - инвестор инвестиция контрактын гамәлгә ашыру кысаларында үзенең һәм (яки) җәлеп ителгән акчаларны куллана торган күчемсез милек объекты (бина, урын, төзелеш, корылма;

- инвестор - инвестиция контрактлары төзү хокукына инвестиция конкурсында җиңгән, инвестиция контракты төзегән һәм үз акчалары, соинвесторларның финанс ресурсларын яки заем акчаларын җәлеп итү хисабына инвестиция проектын финанслауны (финанслашуны) тәэмин итүче физик яки юридик зат.

2. Махсус инвестиция контракты Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә сәнәгать продукциясен җитештерүне булдыру һәм (яисә) үзләштерү максатында махсус инвестиция контрактында каралган вакытка үз көчләре белән яисә башка затларны җәлеп итеп, үз өстенә йөкләмәләр алучы юридик зат яки шәхси эшкуар (алга таба шулай ук - тиешенчә инвестор, җәлеп ителгән зат, инвестиция проекты) белән төзелә.

3. Махсус инвестиция контрактының ягы булган инвесторга һәм (яисә) махсус инвестиция контрактында күрсәтелгән башка затларга карата муниципаль хокукый актларда каралган сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын гамәлгә ашырган очракта, Татарстан Республикасының Балтач район башкарма комитеты махсус инвестиция контрактының яклары булып тора.

4. Махсус инвестиция контракты төзелергә мөмкин булган инвестиция проектларын карау һәм сайлап алу «Балтач муниципаль районының Инвестиция советын төзү турында» 2014 елның 18 июлендәге 135 номерлы Балтач муниципаль районы башлыгы карары белән төзелгән Балтач муниципаль районының инвестиция Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Махсус инвестиция контракты инвестиция проектлары гамәлгә ашырыла торган сәнәгать тармакларында Балтач муниципаль районы муниципаль программаларының бурычларны хәл итү һәм (яисә) максатчан күрсәткечләргә һәм индикаторларга ирешү максатларында, инвестиция проектларына карата төзелә.

6. Махсус инвестиция контрактының типлаштырылган формасы «Сәнәгатьнең аерым тармаклары өчен махсус инвестиция контрактлары турында» 2015 елның 16 июлендәге 708 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган.

7. Махсус инвестиция контракты инвестиция проектының бизнес-планы нигезендә инвестиция проектының оператив проект табышына чыгу вакытына тигез вакытны 5 елга озайтылган, 10 елдан да артык булмаган вакытка төзелә.

8. Инвестиция контракты төзү белән кызыксынган физик яки юридик зат Татарстан Республикасының Балтач район башкарма комитетына түбәндәге документларны җибәрә:

8.1. Юридик затлар булган инвесторлар өчен:

- билгеләнгән форма буенча гариза (1 нче кушымта);

- инвестиция программасы (инвестор аны 3 нче кушымта нигезендә үрнәк буенча мөстәкыйль тутыра);

- барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән оештыру документларының тиешенчә расланган күчермәләре;

- инвесторны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына дәүләт теркәве турында язма кертү хакында таныклык күчермәсе;

- салым органы тамгасы белән, оешманың гариза тапшырган датага бухгалтерлык балансының инвестор раслаган күчермәсе;

- бюджетка салым түләүләре һәм мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмавын раслаучы документ;

- инвесторны бетерү яки үзгәртеп кору факты булмавын яисә инвесторның банкротлык стадиясендә булмавын раслаучы документлар (ЮЗБДРнан (ЕГРЮЛ) өземтә, Татарстан Республикасы Арбитраж суды карары);

- кирәк булган очракта, инвестор исеменнән гамәлләрне башкару өчен затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

8.2. Физик затлар булган инвесторлар өчен (шул исәптән шәхси эшкуарлар өчен):

- билгеләнгән форма буенча гариза (2 нче кушымта);

- инвестиция программасы (инвестор аны 3 нче кушымта нигезендә үрнәк буенча мөстәкыйль тутыра);

- гариза бирүченең паспорт күчермәсе;

- шәхси эшкуар буларак дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (булган очракта яисә шәхси эшкуар булса);

- бюджетка салым түләүләре һәм мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмавынраслаучы документ;

- инвесторның банкротлык стадиясендә булу факты юклыгын раслаучы документ;

- кирәк булган очракта, конкурста катнашучы исеменнән гамәлләрне башкару өчен затның вәкаләтләрен раслый торган документ (ШЭБДРнан (ЕГРИП) өземтә).

9. Аның барышында сәнәгать продукциясен җитештерү төзелә яисә модернизацияләнә торган махсус инвестиция контрактын төзү өчен, дәгъвачы әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза составында сәнәгать җитештерүен булдыруны һәм модернизацияләүне, эш урыннарын булдыруны, сәнәгать продукциясен чыгаруның төзелгән (модернизацияләнгән) куәтләренә һәм җитештерүенә үзләштерүне һәм һәм мәҗбүри тәртиптә инвестиция характерындагы түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыруны раслый торган документлар тапшыра:

9.1. Яңа җитештерү егәрлекләрен булдыру өчен җир кишәрлекләрен сатып алуга яки озак вакытка арендага алуга (инвестиция проекты гамәлгә ашырыла торган җир участогы инвестор яки җәлеп ителгән затлар милкендә булган очраклардан тыш);

9.2. Проект документларын эшләүгә;

9.3. Җитештерү биналарын һәм корылмаларын төзүгә яки реконструкцияләүгә рөхсәт;

9.4. Төп акчаларны сатып алуга, коруга, җитештерүгә, илтеп җиткерүгә, расконсервациягә һәм модернизацияләүгә (инвестиция проектын гамәлгә ашыру барышында сатып алына торган җиһазларның минималь өлеше модернизацияләнә торган һәм (яисә) расконсервацияләнә торган җиһазлар бәясенең кимендә 25 процентын тәшкил итә), шул исәптән таможня пошлиналары һәм таможня җыемнары, шулай ук төзелеш-монтаж һәм эшләтеп җибәрү-көйләү эшләренә.

9.5. Әлеге Тәртипнең 9 пунктында каралган документлар булып инвестиция проектының бизнес-планы, Инвестиция килешүе (килешүләре) яисә инвестиция проектын гамәлгә ашыруда өченче затларның катнашу тәртибен билгели торган инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында башлангыч шартнамә (шартнамәләр) күчермәсе (булганда).

10. Аның барышында иң яхшы үтемле технологияләр кертелә торган махсус инвестиция контракты төзү өчен, дәгъвачы әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза составында «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, иң яхшы үтемле технологияләрне гамәлгә кертүне раслаучы документлар тапшыра:

10.1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән килештерелгән әйләнә-тирә мохитне саклау чаралары планы (II һәм III категорияле объектлар өчен);

10.2. «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелә торган ведомствоара комиссия тарафыннан хупланган экологик нәтиҗәлелекне күтәрү программасы (I категорияле объектлар өчен);

10.3. Инвестиция килешүе (килешүләре) яисә инвестиция проектын гамәлгә ашыруда өченче затларның катнашу тәртибен билгели торган инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында башлангыч шартнамә (шартнамәләр) күчермәсе. (булганда)

11. Сәнәгать продукциясен җитештерү үзләштерелә торган махсус инвестиция контракты төзү өчен инвестор әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза составында инвестор инвестиция проектын гамәлгә ашыру барышында җирлектә аналоглары булмаган сәнәгать продукциясен җитештерүнең үзләштерелүен раслаучы документларны һәм инвестиция килешүе (килешүләре) яисә инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында башлангыч шартнамә (шартнамәләр) күчермәсен (булганда) тапшыра.

12. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты икътисад һәм фаразлау бүлеге белгечләре Балтач муниципаль районының инвестиция Советы белән берлектә кергән гаризаны терки һәм әлеге Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән таләпләр нигезендә әлеге Тәртипнең 8-11 пунктларында күрсәтелгән документларны теркәү датасыннан биш эш көне эчендә түбәндәгеләрне башкара:

- үз компетенциясе кысаларында алынган документларны карыйлар;

- махсус инвестиция контракты төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында бәяләмәне, шулай ук «Сәнәгатьнең аерым тармаклары өчен махсус инвестиция контрактлары турында» 2015 елның 16 июлендәге 708 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган типлаштырылган форма буенча вәкаләтле орган тарафыннан төзелгән махсус инвестиция контракты проектын әзерлиләр һәм Балтач муниципаль районының инвестиция Советына җибәрәләр.

13. Инвестор һәм җәлеп ителгән зат (булган очракта) махсус инвестиция контракты проекты кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә кул куелган махсус инвестиция контрактын яисә язма рәвештә инвесторның яки җәлеп ителгән затның (булган очракта) махсус инвестиция контрактын имзалаудан баш тарту кәгазен җибәрәләр.

14. Инвестор һәм җәлеп ителгән зат (булган очракта) тарафыннан имзаланган махсус инвестиция контракты алынганнан соң 10 эш көне эчендә, ә инвесторга һәм (яки) җәлеп ителгән затка карата муниципаль хокукый актларда каралган кызыксындыру чаралары гамәлгә ашырылган очракта, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты махсус инвестиция контрактына кул куя.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
территориясендә махсус инвестиция
контрактын төзү тәртибе турында
Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Инвестицияләү объектын төзүгә, реставрацияләүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонт ясауга һәм төзелешен тәмалауга ГАРИЗА (юридик зат өчен)

1. Инвестиция контракты объекты:
1.1. Объектның тулы исеме ________________________________________
1.2. Объектның адресы ______________________________________________
1.3. Милек: ______________________________________________________
1.4. Баланста тотучы _____________________________________________
1.5. Объектның кыскача сыйфатламасы _______________________________
2. Инвестор (юридик зат):
2.1. Тулы исеме ___________________________________________
2.2. Урнашу урыны ___________________________________________
2.3.Оештыру-хокукый формасы _________________________________
2.4. Дәүләт теркәве номеры һәм датасы ________________________
2.5. Банк реквизитлары ___________________________________________
3. Инвестиция контракты буенча төп тәкъдимнәр:
3.1. Инвестицияләү объектын төзү, реставрацияләү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау яки төзеп бетерү буенча планлаштырылган төп эшләр
______________________________________________________________________
3.2. Инвестицияләр кертү вакыты буенча планлаштырылган инвестицияләр күләме
______________________________________________________________________
______________________________ __________________ __________________
(вазыйфасы, ФИА) (имза, дата)

М.У.
(Инвестиция контракты төзүгә гаризаны имзалау хокукын раслый торган документның исеме, номеры һәм датасы)

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
территориясендә махсус инвестиция
контрактын төзү тәртибе турында
Нигезләмәгә
2 нче кушымта

Инвестицияләү объектын төзүгә, реставрацияләүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонт ясауга һәм төзелешен тәмалауга ГАРИЗА (физик зат өчен)

1. Инвестиция контракты объекты:
1.1. Объектның тулы исеме ________________________________________
1.2.Объектның адресы _____________________________________________
1.3. Милек: ______________________________________________________
1.4. Балансга тотучы _______________________________________________
1.5.Объектның кыскача сыйфатламасы ________________________________
2. Инвестор (физик зат - шәхси эшкуар):
2.1.Фамилиясе, исеме, атасының исеме _______________________________
2.2. Паспорт мәгълүматлары: сериясы _______ номеры_____________,
кем тарафыннан һәм кайчан бирелде __________________________________
2.3. Яшәү урыны адресы ______________________________________________
2.4. Дәүләт теркәве турында таныклык ___________________________
2.5. Исәп-хисап счеты номеры _______________________________________
3. Инвестиция контракты буенча төп тәкъдимнәр:
3.1. Инвестицияләү объектын төзү, реставрацияләү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау яки төзеп бетерү буенча планлаштырылган төп эшләр
______________________________________________________________________
3.2. Инвестицияләр кертү вакыты буенча планлаштырылган инвестицияләр күләме _______________________________________________

_____________________________ ___________________ ______________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имза, дата)

(Инвестиция контракты төзүгә гаризаны имзалау хокукын раслый торган документның исеме, номеры һәм датасы)

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
территориясендә махсус инвестиция
контрактын төзү тәртибе турында
Нигезләмәгә
3 нче кушымта

Инвестиция контракты кысаларында инвестицияләү объектын төзү, реставрацияләү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау яисә төзү эшләрен тәмамлау буенча ИНВЕСТИЦИЯ ПРОГРАММАСЫ

Әлеге программаның максаты - инвестицияләү объектын төзүгә, реставрацияләүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга яисә төзүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген билгеләү. Төзелеш, реставрация, реконструкция, капиталь ремонт үткәрелгәннән соң яисә төзеп бетерелгәнән соң объектның планлаштырылган билгеләнеше:

______________________________________________________________________

Объектның сыйфатламасы һәм техник торышы:

______________________________________________________________________

Инвестиция контракты кысаларында планлаштырылган эшләр, вакытлар һәм чыгымнар:

______________________________________________________________________

Инвестиция проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәләренә инвестиция контракты якларының милек хокуклары күләме (нигезләү белән):

баланста тотучы - ____________________;

инвестор - ____________________________.

Кушымталар:

1. Планлаштырылган эшләргә башлангыч сметалар.
2. Объект төзелешен тәмамлау буенча план-график.